**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 апрель № 227

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1036 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче, 2015 ел, 09 декабрь, 929 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге (02.01.04*).»;

4.1.20 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2008 ел, 21 апрель, 258 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; ,2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы, 2015 ел, 02 февраль, 49 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Кодификаторның «Өченче» графасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | «02.01.04 | Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге». | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карар белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 15 апрель, 227 нче карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы структурасы

